ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Иннополис шәһәре территориясендә югары дәрәҗәдә автоматлаштырылган транспорт чараларын эксплуатацияләү буенча цифрлы инновацияләр өлкәсендә эксперименталь хокукый режим урнаштыру мөмкинлеге турында

«Яндекс.Испытания» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Россия Федерациясендә цифрлы инновацияләр өлкәсендә эксперименталь хокукый режимнар турында» 2020 елның 31 июлендәге 258-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы $5^1$ өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Иннополис шәһәре территориясендә югары дәрәҗәдә автоматлаштырылган транспорт чараларын эксплуатацияләү буенча цифрлы инновацияләр өлкәсендә эксперименталь хокукый режим урнаштыру мөмкинлеге турындагы инициатив тәкъдимен карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Иннополис шәһәре территориясендә югары дәрәҗәдә автоматлаштырылган транспорт чараларын эксплуатацияләү буенча цифрлы инновацияләр өлкәсендә эксперименталь хокукый режим урнаштыру мөмкинлеге белән килешергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2021 елның 23 сентябре
№ 1081-VI ДС